КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 август г.Казань № 792

«(52-57 Чишмә-КНС) 35 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру максатларында «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте мәнфәгатьләрендә гавами сервитут билгеләү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының V[7] бүлеге, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның [25] октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының саклау зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус шартларын билгеләү тәртибе турында» 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы нигезендә, «(52-57 Чишмә-КНС) 35 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. »(52-57 Чишмә-КНС) 35 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру максатларында «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте (ИНН 1655049111, ОГРН 1021602830930) мәнфәгатьләрендә кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләренә (алга таба – җир кишәрлекләре) карата 49 елга гавами сервитут (алга таба – гавами сервитут) билгеләргә.

2. Бу карарга теркәлгән «(52-57 Чишмә-КНС) 35 кВ һава линиясе» төбәк әһәмиятендәге электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру максатларында гавами сервитут чикләре урнашу урынының график тасвирламасын расларга.

3. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

«Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның $3^{6}$ статьясындагы 4 пункты нигезендә гавами сервитут өчен түләү билгеләнми;

җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану нигезендә алардан файдалану мөмкин булмаячак яки шактый авыр булачак срогы гавами сервитут срогына туры килә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бу карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә законнар белән билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

бу карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә рәсми бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының башкарма комитетына җибәрүне;

бу карарның күчермәләрен җир кишәрлекләренең хокук ияләренә, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, «Сетевая компания» акционерлык җәмгыятенә җибәрүне.

5. «Сетевая компания» акционерлык җәмгыятенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

җир кишәрлекләренең хокук ияләре белән гавами сервитутны гамәлгә ашыру турында килешү төзүне;

федераль дәүләт энергетика күзәтчелеген гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының саклау зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус шартларын билгеләү тәртибе турында» 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары нигезендә бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән объектка карата саклау зонасы чикләрен килештерү турындагы гариза белән мөрәҗәгать итәргә;

электр челтәре хуҗалыгы объектына техник хезмәт күрсәтү буенча тәэмин ителеше өчен гавами сервитут билгеләнгән план (регламент) эшләрен елга бер тапкыр гамәлгә ашыруны;

җир кишәрлекләрен аларның рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерүне;

гавами сервитут нигезендә урнаштырылган инженерлык корылмасын, тәэмин ителеше өчен гавами сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{50}$ статьясында билгеләнгән срокларда сүтүне.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин